КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2026 ел, 4 май г.Казань № 661

2026 елның 9 маенда алкогольле продукцияне ваклап сатуны чикләү турында

«Этил спирты, алкогольле һәм спиртлы продукция җитештерүне һәм аларны әйләнештә йөртүне дәүләт җайга салуы турында һәм алкогольле продукцияне куллануны (эчүне) чикләү хакында» 1995 елның 22 ноябрендәге 171-ФЗ Федераль закон нигезендә, 2026 елның 9 маенда 1941 – 1945 еллар Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 81 еллыгын бәйрәм итүгә багышланган тантаналы чараларны үткәргәндә иминлекне тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. 2026 елның 9 маенда 1941 – 1945 еллар Бөек Ватан сугышында Җиңүнең 81 еллыгын бәйрәм итүгә багышланган тантаналы чараларны үткәрү көнендә алкогольле продукцияне ваклап сату (җәмәгать туклануы хезмәтләрен күрсәткәндә, Казан шәһәренең Астрономия, Бауман, Бондаренко (Ямашев проспекты белән кисешкән урыннан алып Маршал Чуйков урамы белән кисешкән урынга кадәр), Большая Красная (Япеев урамы белән кисешкән урыннан алып Толстой урамы белән кисешкән урынга кадәр), Гоголь, Дзержинский, Жуковский, Кави Нәҗми, Карл Маркс (Япеев урамы белән кисешкән урыннан алып «Корстон» кунакханә сәүдә-күңел ачу комплексына кадәр), Карл Фукс, Коротченко, Сул як Болак (Ташаяк урамы белән кисешкән урыннан алып Чернышевский урамы белән кисешкән урынга кадәр), Лобачевский, Малая Красная, Максим Горький, Маршал Чуйков (Мусин урамы белән кисешкән урыннан алып Бондаренко урамы белән кисешкән урынга кадәр), Миславский, Мәскәү (Ташаяк урамы белән кисешкән урыннан алып Чернышевский урамы белән кисешкән урынга кадәр), Мусин (Ямашев проспекты белән кисешкән урыннан алып Маршал Чуйков урамы белән кисешкән урынга кадәр), Муса Җәлил, Мөштәри (Большая Красная урамы белән кисешкән урыннан алып Щапов урамы белән кисешкән урынга кадәр), Николай Ершов («Корстон» кунакханә сәүдә-күңел ачу комплексыннан алып Вишневский урамы белән кисешкән урынга кадәр), Уң як

Болак (Ташаяк урамы белән кисешкән урыннан алып Чернышевский урамы белән кисешкән урынга кадәр), Профсоюз, Профессор Нужин, Пушкин («Милли китапханә» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе бинасыннан алып Галактионов урамы белән кисешкән урынга кадәр), Рахматуллин, Ташаяк, Театр, Толстой, Университет, Чернышевский (Дзержинский урамы белән кисешкән урыннан алып Уң як Болак урамы белән кисешкән урынга кадәр) урамнарында; Саначин тыкрыгында; 1 Май мәйданында, Ирек мәйданында, Меңьеллык мәйданында; Ямашев проспектында (Бондаренко урамы белән кисешкән урыннан алып Фатих Әмирхан урамы белән кисешкән урынга кадәр); Кремль яр буенда, шулай ук Горький исемендәге Үзәк мәдәният һәм ял паркы, Җиңү паркы, «Черек күл» паркы, Ленин бакчасы, Бакый Урманче исемендәге сквер, Илһам Шакиров исемендәге сквер, Лев Толстой исемендәге сквер, Константин Котельников скверы, Медицина хезмәткәрләре скверы, Лобачевский урамындагы сквер, «Казан» гаилә үзәге янындагы парк кебек җәмәгатьчелек киңлекләре территорияләрендә урнашкан сәүдә объектларында алкогольле продукцияне ваклап сатудан тыш) рөхсәт ителми дип билгеләргә.

2. Республика «Татмедиа» матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгына, Казан шәһәре муниципаль берәмлеге башкарма комитеты белән берлектә, халыкка кертелә торган чикләү турында мәгълүмат бирү эшен оештырырга.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Этил спирты, алкогольле продукция җитештерүне, әйләнештә йөртүне һәм аларның сыйфатын дәүләт тикшерүендә тотуны тәэмин итү һәм кулланучылар хокукларын яклау буенча дәүләт инспекциясенә һәм килешү буенча Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгына йөкләргә.

4. Бу карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин